**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

19.11.2025 № 419

**Татарстан Республикасында газ кертү буенча төбәк штабы составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында газ кертү буенча төбәк штабын төзү турында» 2022 елның 18 февралендәге 97 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 2 сентябрендәге 284 номерлы һәм 2022 елның 10 декабрендәге 390 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында газ кертү буенча төбәк штабы составына (алга таба – төбәк штабы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

төбәк штабы составыннан А.С. Груничевны, А.А. Родченконы чыгарырга;

төбәк штабы составына кертергә:

Газизуллин Булат Булат улын – «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урта Идел филиалы директорын (килешү буенча);

Гайнетдинов Ренат Вагыйзь улын – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисен;

Калабанов Дмитрий Евгеньевичны – «Инженерлык карарлары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорын (килешү буенча);

Нуриәхмәтов Рөстәм Хөсәен улын – Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе житәкчесен (килешү буенча);

Софронов Александр Александровичны – «Газпром төбәкарагаз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Хакимият органнары һәм төбәкләр белән эшләү идарәсенең төбәкләр белән эшләү бүлеге башлыгын (килешү буенча);

Ставецкий Георгий Павловичны – «Газпром төбәкарагаз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Газлаштыру идарәсе башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

Хряпин Сергей Игоревичны – «Газпром төбәкарагаз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Хакимият органнары һәм төбәкләр белән эшләү идарәсенең төбәкләр белән эшләү бүлеге баш белгечен (килешү буенча);

төбәк штабы әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Н. Миңнехановның – «Татарстан Республикасы Рәисе, төбәк штабы рәисе»;

Р.М. Галиевның – «Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе»;

М.Р. Зариповның – «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды башкарма директоры (килешү буенча)»;

А.Э. Таһировның – «Газпром төбәкарагаз Казан» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**